**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2021елнын 14 апреле 108№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының административ комиссиясе турында

2005 елның 30 декабрендәге «Муниципаль район һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2021 елның 3 мартындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 34 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты Карар итә:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының административ комиссиясен төзергә.

2. Расларга:

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының административ комиссиясе составын (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы административ комиссиясенең эш регламентын (2 нче кушымта).

4.Әлки муниципаль районының административ комиссиясенең вәкаләтләре вакыты әлеге административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана һәм биш ел дәвам итә.

5. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2007.13.07, 227№ карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2009.04.05, 111(а)№ «Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2007 елның 13 июлендәге 227 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында " гы карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2010.20.12, 509№ «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы административ комиссия составын раслау турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2011.22.09, 510№ «Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты 2011.10.05, 288№ карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

«Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты 2010.20.12, 509№ карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 02 июлендәге 378 номерлы «Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 14 мартындагы 112 номерлы «Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2012.27.01, 41№ карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2013.06.02, 69№ «Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 22 октябрендә кабул ителгән 558 номерлы «Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2012.02.07,378№ карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2013.14.03 130№ «Административ хокук бозулар турында беркетмә төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге хакында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2014.17.01, 6 № «Әлки муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 4 октябрендәге 435 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2014.17.11, 69 № «Әлки муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 17 ноябрендәге 490 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2015.25.07 240№«Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге хакында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2016.27.01, 6№ «Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 26 августындагы 263 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2016.13.05, 88№ карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017.20.02 49№ «Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 сентябрендәге 313 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017.06.07 269№ «Әлки муниципаль районы Башкарма

комитетының 2017 елның 13 маендагы 163 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018.08.01 8№ «Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 6 июлендәге 269 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018.22.08 323№ «Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 6 апрелендәге 152 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2013.14.03 130№ «Административ хокук бозулар турында беркетмә төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2019.22.05 206№ «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге хакында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020.13.02 51№ «Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 августындагы 323 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020.26.08 88№ карарын,

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020.06.08 285№ «Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 15 июнендәге 220а номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын.

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче: И. В. Юсупов

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2021.14.04 108№ карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының административ комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| **Сәләхиева Лилия Равил кызы** | ТР Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре идарәчесе, **комиссия рәисе;** |
| **Сорин Алексей Владимирович** | ТР Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, **рәис урынбасары** (килешү буенча ); |
| **Хафизова Миләүшә Фәргать кызы** | Әлки муниципаль районы административ комиссиясенең **җаваплы сәркатибе;** |
| **Мирзазанов Раил Рафис улы** | ТР Әлки районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының ПУУ һәм ББЭП бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| **Зәйнуллин Илсур Таһир улы** | "Әлки урманчылыгы" ДКУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| **Советникова Маргарита Анатольевна** | Әлки муниципаль районы Советының гомуми бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| **Әхмәтҗанова Алсинә Марат кызы** | Әлки муниципаль районы Советының юридик бүлеге начальнигы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2021.14.04 108№ карарына 2 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының административ комиссиясе эш регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы административ комиссиясе (алга таба - административ комиссия) эшчәнлегенең эчке мәсьәләләрен, шул исәптән административ комиссия утырышын алып бару тәртибен, административ комиссия әгъзалары арасында эш бүлүне билгели.

2. Административ комиссия 2005 елның 30 декабрендәге «Муниципаль район һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелә.

3. Административ комиссия Татарстан Республикасының Административ хокук бозулар турында кодексында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

4.Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары карарлары, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, муниципаль хокукый актлар, башка норматив-хокукый актлар, шулай ук әлеге регламент нигезендә гамәлгә ашыра.

5. Административ комиссиянең мөһере һәм чыгымнар сметасы бар.

6.Административ комиссияне финанс белән тәэмин итү җирле бюджетка Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## II. Административ комиссия эшен оештыру

7. Административ комиссия рәисеннән, рәис урынбасарыннан, җаваплы сәркатиптән һәм административ комиссия әгъзаларыннан тора.

8. Административ комиссия белән административ комиссия эшен оештыручы рәис җитәкчелек итә.

9. Даими түләүле нигездә административ комиссия составына җаваплы сәркатип керә.

10.Рәис, рәис урынбасары, административ комиссия әгъзалары административ комиссиядә җәмәгать башлангычларында эшлиләр.

11.Үз вазыйфаларын даими түләүле нигездә башкаручы җаваплы сәркатип, хезмәт өчен түләү шартлары буенча муниципаль хезмәткәрләргә тиңләштерелә.

12. Административ комиссиянең санлы составы 7 әгъзадан да ким булмаган һәм так санда билгеләнә.

13.Административ комиссия әгъзасы итеп 21 яшькә җиткән, югары белемле, язма рәвештә аны комиссия составына кертүгә ризалык белдергән Россия Федерациясе гражданы билгеләнергә мөмкин. Административ комиссиянең җаваплы сәркатибе югары белемле булырга тиеш.

14.Административ комиссия үз эшен һәр эшнең шартларын тулысынча, объектив, һәрьяклап һәм үз вакытында ачыклау, аны гамәлдәге законнар таләпләренә төгәл туры китереп хәл итү нигезендә гамәлгә ашыра.

## III. Административ комиссия әгъзаларының вәкаләтләре

15.Административ комиссия әгъзалары административ хокук бозу турындагы эшне караганда тигез хокукка ия.

16. Административ комиссия әгъзалары вәкаләтле:

1) административ комиссия утырышларын әзерләүдә катнашырга;

2) алдан, административ комиссия утырышына кадәр, карап тикшерүгә кертелгән административ хокук бозулар турындагы эш материаллары белән танышырга;

3) административ комиссия рәисенә эш шартларын өстәмә ачыклауда кирәк булган очракларда эшне карауны кичектерү турында тәкъдим кертергә;

4) административ комиссия утырышында катнашырга;

5) административ хокук бозу турындагы эш буенча производствода катнашучы затларга сораулар бирергә;

6) карала торган эшләр буенча административ комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарлар, билгеләмәләр һәм тәкъдимнәр буенча фикер алышуда катнашырга;

7) административ комиссия тарафыннан карала торган эшләр буенча карарлар, билгеләмәләр һәм тәкъдимнәр кабул иткәндә тавыш бирүдә катнашырга;

8) административ комиссия утырышына килмәгән затларга административ комиссия карарларын җибәрүне гамәлгә ашырырга;

9) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга.

17.Административ комиссия рәисе административ комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) административ комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра, рәис урынбасары һәм җаваплы сәркатип арасында вазыйфаларны бүлә, аларның закон белән бирелгән вәкаләтләр

чикләрендә функцияләрен билгели, бу тиешле боерык яисә административ комиссия буенча күрсәтмә белән беркетелә;

2) административ комиссия утырышларында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

3) административ комиссия эшен планлаштыра;

4) кадрлар сайлау, шулай ук административ комиссия рәисе урынбасарының һәм әгъзаларының квалификациясен күтәрү эшен оештыра;

5) административ комиссиянең һәр утырышының көн тәртибен раслый;

6) административ комиссия утырышларын билгели;

7) административ комиссия утырышларында кабул ителгән карар, билгеләмә һәм күрсәтмәләргә кул куя;

8) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар һәм гражданнар белән мөнәсәбәтләрдә административ комиссия мәнфәгатьләрен тәкъдим итә;

9) административ комиссия эшчәнлеге өчен шәхси җаваплылык тота.

18. Административ комиссия рәисе урынбасары административ комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) административ комиссия рәисе йөкләмәләрен үти;

2) административ комиссия рәисе булмаганда яисә үз бурычларын үти алмаганда аның вазыйфаларын башкара.

19.Административ комиссиянең җаваплы сәркатибе административ комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) административ хокук бозулар турындагы эшләрне административ комиссия утырышында карауга әзерләүне гамәлгә ашыра;

2) административ комиссия рәисе, аның урынбасары йөкләмәләрен үти;

3) административ комиссия эшенә техник хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыра;

4) административ комиссия эшен алып бара;

5) административ комиссия әгъзаларына һәм административ хокук бозу турындагы эш буенча производствода катнашучы затларга эшне карау вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

6) административ хокук бозулар турында карала торган эшләр буенча административ комиссия тарафыннан чыгарылган карар, билгеләмә һәм тәкъдимнәр проектларын әзерләүне һәм рәсмиләштерүне административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы белән билгеләнгән таләпләргә туры китереп гамәлгә ашыра;

7) карарларның күчермәләрен үз вакытында бирүне яисә аларны җибәрүне контрольдә тота;

8) эш буенча производствода катнашучы затларның, башка физик һәм юридик затларның административ комиссия тарафыннан чыгарылган карар, билгеләмә һәм тәкъдимнәрен үтәлешен тикшереп тора.

Җаваплы сәркатип булмаган очракта, аның вазыйфаларын административ комиссия рәисе билгеләгән административ комиссия әгъзаларының берсе башкара.

20.Әлки муниципаль районының административ комиссиясенең вәкаләтләре вакыты әлеге административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана һәм биш ел тәшкил итә.

21. Административ комиссия әгъзасы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла:

1) административ комиссия әгъзасы тарафыннан үз вәкаләтләрен туктату турында язма гариза биргәндә;

2) административ комиссия әгъзасы булган затка карата судның гаепләү карары законлы көченә кергәндә;

3) административ комиссия әгъзасы булып торучы затны, законлы көченә кергән суд карары белән эшкә сәләтсез, эшкә сәләте чикләнгән, хәбәрсез килмәгән яисә вафат булган дип таныганда;

4) административ комиссия утырышларында эшендә сәбәпсез административ комиссия әгъзасы вазыйфаларын берничә тапкыр үтәмәү;

5) административ комиссия әгъзасы вәкаләтләрен үтәүгә тоткарлык ясаучы медицина бәяләмәсе булу;

6) административ комиссия әгъзасының намусына һәм абруена китерә торган гамәлләр кылу;

7) административ комиссия әгъзасының үлеме;

8) Россия Федерациясе законнарында каралган башка очракларда.

22. Башкарма комитет вакытыннан алда үз вәкаләтләрен туктаткан административ комиссия әгъзасы урынына административ комиссиянең яңа әгъзасын билгели.

## IV. Административ комиссия утырышын алып бару тәртибе

23.2005 елның 30 декабрендәге «Муниципаль район һәм шәһәр округларының жирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә административ хокук бозулар турындагы эшләр рәис, рәис урынбасары, җаваплы сәркатип һәм административ комиссия әгъзалары, эштә катнашучы башка затлар, аларның вәкилләре составында административ комиссия тарафыннан аның утырышларында карала.

24.Административ комиссия утырышлары атна саен (кирәк булганда) пәнҗешәмбе (эш көне булып торган) 14.00 сәгатьтән башлап, әгәр административ комиссия рәисе тарафыннан бүтән дата һәм (яки) карау вакыты билгеләнмәсә, үткәрелә.

25.Административ комиссия утырышында административ комиссия рәисе, ә ул булмаганда - административ комиссия рәисе урынбасары рәислек итә.

26.Административ комиссия утырышлары, кагыйдә буларак, ачык һәм хәбәрдар булып тора. Аларда массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала. Административ комиссия утырышы вакытында кино, видео һәм фотога төшерү административ комиссия рәисе рөхсәте белән башкарыла.

27.Административ комиссия карары буенча аның утырышлары ябык булырга мөмкин. Аларда административ комиссия әгъзалары, хокук саклау органнары җитәкчеләре һәм махсус чакырылган затлар гына катнаша ала.

28.Административ комиссия утырышлары утырышлар залында законнар таләпләрен үтәп үткәрелә, ә булмаганда, башка биналарда эшләрне карау рөхсәт ителә.

29. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы белән билгеләнгән срокларда тәэмин ителә.

30. Административ комиссия үз утырышларын административ комиссия эшенең графигы (планы) нигезендә атна саен үткәрә.

31. Административ комиссия утырышы составының кимендә өчтән ике өлеше катнашканда тулы хокуклы.

32. Административ комиссия утырышын әзерләүне җаваплы сәркатип башкара, ул карауга билгеләнгән эшләр исемлеген төзи, рәислек итүчегә эшне карау мөмкинлеге турында хәбәр итә, якларның килүен һәм вәкаләтләрен, шулай ук өстәмә материалны тикшерә.

33. Административ хокук бозу турындагы эшне тикшерү өчен билгеләнгән вакытта рәислек итүче административ комиссия утырышын ача, административ комиссия составын игълан итә, эштә катнашучыга хокук һәм бурычларны аңлата, утырышны алып бару тәртибен билгели, административ процесста катнашучыларның гариза, үтенечнамәләре булу - булмавын барлый, утырыш белән җитәкчелек итә, барлык хәлләрне тулы һәм һәрьяклы ачыклауга ярдәм итә, утырышта тиешле тәртип тәэмин итә.

34. Беркетмәне карау рәислек итүченең административ материал торышы турындагы докладыннан башлана. Доклад тәмамланганнан соң административ комиссия әгъзалары карала торган эшнең асылы буенча сораулар бирергә хокуклы.

35. Әгәр административ комиссия утырышына чакырылучы административ эш буенча якларның вәкилләре килсә, рәис, рәис урынбасары, административ комиссия әгъзалары аларга сораулар бирергә хокуклы.

36.Административ эш буенча докладтан соң административ комиссия беркетмә буенча фикер алышуга күчә, анда административ комиссия әгъзалары гына катнаша.

37. Административ комиссия карары утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

38.Административ комиссия карарларына административ комиссия утырышында рәислек итүче имза сала.

39. Административ комиссия законда билгеләнгән тәртиптә шулай ук билгеләмәләр һәм күрсәтмәләр чыгарырга мөмкин.

40. Рәислек итүче утырышта катнашучы затларга һәм аларның вәкилләренә административ комиссия карарын игълан итә, шулай ук административ комиссия карарына шикаять бирү тәртибен аңлата.

41. Административ комиссия карарларына карата шикаятьләр яисә протестлар административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә карала.

42. Карар күчермәсе имза куйдыртып бирелә яки карар чыгарылган затка өч көн эчендә җибәрелә. Әгәр карарның күчермәсе җибәрелә икән, эштә тиешле язма ясала.

43. Эшне кичектерү, тәнәфес игълан итү һәм эшне яңадан карау гамәлдәге закон таләпләрен үтәп башкарыла.

44. Административ комиссиянең һәр утырышында җаваплы сәркатип тарафыннан башкарыла торган беркетмә алып бару мәҗбүри. Беркетмә административ комиссия утырышы тәмамланганнан соң өч көннән дә соңга калмыйча административ комиссия рәисе һәм җаваплы сәркатибы тарафыннан әзерләнергә һәм имзаланырга тиеш.

## IV. Административ җәза салу турында карарларның үтәлеше

45. Административ комиссия карарлары барлык дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар, гражданнар һәм аларның берләшмәләре, юридик затлар тарафыннан үтәлергә тиеш.

46. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар законлы көченә кергәннән соң үтәлергә тиеш.

47. Административ комиссиянең закон көченә кергән карарын үтәү Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

48. Административ штраф административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан административ штраф салу турында карар законлы көченә кергән көннән алтмыш көннән дә соңга калмыйча яисә административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 31.5 статьясында каралган кичектереп тору срогы чыккан көннән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.

49. Административ штраф суммасы административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан банкка яки башка кредит оешмасына түләнелә яки күчерелә.

50. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карарга карата шикаять гамәлдәге законнар нигезендә карарның күчермәсен тапшырганнан яки алганнан соң ун тәүлек эчендә район судына тапшырылырга мөмкин.

51.Карар законлы көченә кергән көннән алтмыш көн узгач административ штрафны түләү турында таныклаучы документ булмаганда, административ комиссия федераль законнарда каралган тәртиптә административ штраф суммасын түләтү өчен суд приставына-башкаручыга тиешле материалларны җибәрә.

52.Штраф салу рәвешендәге административ җәза гаепле затларны җибәрелгән хокук бозуларны бетерү кирәклегеннән азат итми.

## V. Административ комиссия эше

53. Административ комиссиядә билгеләнгән форма буенча статистик хисап алып барыла. Статистик хисаплылыкны дөрес һәм үз вакытында тапшырган өчен җаваплылык административ комиссия рәисенә, ә ул булмаганда административ комиссия рәисе урынбасарына йөкләнә.

54.Карар чыгарганчыга кадәр, законнарда каралган очраклардан тыш, административ хокук бозулар буенча эшләрне кемгә дә булса бирү тыела.

55. Административ комиссия эшчәнлеген яхшырту максатларында суд-арбитраж практикасын даими гомумиләштерү үткәрелә. Суд-арбитраж практикасын гомумиләштерү нәтиҗәләрен исәпкә алып, законнарны өйрәнү, административ комиссия рәисе урынбасарының һәм аның әгъзаларының квалификациясен күтәрү буенча эш оештырыла.

56. Административ комиссиядә мәгълүмати-белешмә эше алып барыла.

57. Административ комиссиядә килүчеләрне кабул итү бара. Административ комиссия адресына гражданнардан һәм юридик затлардан кергән шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.

58. Административ хокук бозулар буенча эшләр административ комиссиядә саклана һәм биш ел үткәннән соң юкка чыгарылырга тиеш.

59. Административ комиссия эше турында документлар (утырыш беркетмәләре, планнар) административ комиссиядә саклана һәм өч ел юкка чыгарылырга тиеш.

60. Административ хокук бозулар буенча эшләр, административ комиссия эше турында документлар (утырыш беркетмәләре, планнар) сакланырга тиеш булмаган документларны юк итү турында акт нигезендә юкка чыгарыла.

Сакланырга тиеш булмаган документларны юк итүгә бүлеп бирү турындагы акт юкка чыгарыла торган документларның характеристикасын, шулай ук аларны юк итү тәртибен үз эченә алырга, административ комиссия рәисе имзаларга тиеш.